| МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

08.10.2018 г. Казань № под-1458/18

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгында вазыйфаи бурычларны үтәү дәүләт серен тәшкил иткән белешмәләрне куллану белән бәйле булган, аларга билгеләгәндә конкурс үткәрелмәскә мөмкин булган дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2016 елның 9 ноябрендәге под-2201/16 номерлы боерыгына үзгәреш кертү турында

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясындагы 3 өлеше нигезендә б о е р а м:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгында вазыйфаи бурычларны үтәү дәүләт серен тәшкил иткән белешмәләрне куллану белән бәйле булган, аларга билгеләгәндә конкурс үткәрелмәскә мөмкин булган дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2016 елның 9 ноябрендәге под-2201/16 номерлы боерыгы белән расланган (Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 24.01.2017 №под-103/17, 05.04.2017 № под-560/17, 11.05.2017 № под-828/17, 18.10.2017 № под-1678/17 боерыклары белән үзгәрешләр кертелгән) Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгында вазыйфаи бурычларны үтәү дәүләт серен тәшкил иткән белешмәләрне куллану белән бәйле булган, аларга билгеләгәндә конкурс үткәрелмәскә мөмкин булган дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлегенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

исемлеккә түбәндәге эчтәлекле 18 пункт өстәргә:

| | |
|---|---|
| «18. | Опека, попечительлек һәм педагогик ярдәм бүлеге башлыгы» |

2. Кадрлар сәясәте бүлегенә боерык кабул ителгән көннән башлап эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә аны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә җибәрергә.

3. Бу Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары – министр Р.Т.Борһанов